ЧӘРШӘМБЕ
14 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 36 (5836)
*Аерым номеры 10 тиен*

*БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!*

# КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

*РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:*
*Казан, Матбугат йорты.*
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

## ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕН КОММУНИСТИК ТӘРБИЯЛӘҮ ИҢ ӘҺӘМИЯТЛЕ БУРЫЧЛАРНЫҢ БЕРСЕ

Илебез сыйныфсыз социалистик җәмгыят төзелешен тәгәлләү һәм социализмнан коммунизмга тезем-ле рәвештә күчү чорына керде. Бу чорда **хезмәт ияләренә коммунистик тәрбия бирү эше, кешеләрнең аңында капитализм калдыкларын бетерү эше хәл иткеч әһәмияткә ия булып тора.** Партиябезнең XVIII нче съезды тарафыннан хуҗалык һәм культура төзелеше өлкәсендә ил алдына куелган гаят зур тарихи бурычларны уңышлы үтәү, һич шиксез, хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләү мәсьәләсенә нык бәйләнгән.

Коммунистик тәрбия—ул, кешеләрнең аңын үзгәртү, аларның аңында капитализм калдыкларын тәмам бетерү, иске җәмгыятнең начар тапларын, гореф-гадәтләрен, традицияләрен бетерү, миллионнарча кешеләрне хезмәткә һәм җәмагат милкенә социалистик караш рухында тәрбияләү, бөек Ватаныбызның ялкынлы патриотлары, коммунизм җәмгыятен аңлы һәм актив төзүчеләр итеп тәрбияләү дигән сүз.

Безнең илебездә барлык эксплоататор сыйныфлар бетерелде, кешенең кешене эксплоатацияләве һәм җәмгыятнең эксплоататорларга һәм эксплоатацияләнүчеләргә бүленүен тудырган сәбәпләр тулысынча юкка чыгарылды. Социализм җәмгыяте хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүнең гүзәл мәктәбе булып тора. Безнең илнең экономик нигезен социалистик милек тәшкил итә. Димәк, хезмәт ияләре эксплоататорлар өчен түгел, ә социалистик дәүләт өчен, үзләре өчен эшлиләр. Советлар Союзында хезмәт—намус эшенә, дан эшенә, геройлык һәм батырлык эшенә әверелде.

Эшчеләрнең, крестьяннарнең һәм интеллигенциянең абсолют күпчелеге хезмәткә, җәмагат милкенә социалистик караштa тора, алар илнең байлыгын арттыру өчен, Ватаныбызның оборона куәтен тагын да ныгыту өчен үз-үзләрен аямыйча эшлиләр. Социалистик стройның төрле өлкәләрендә намус белән эшләгәнлекләре өчен, аеруча батырлык күрсәткәнлекләре өчен иң кыйммәтле, иң югары бүләк белән—Советлар Союзының орденнары һәм медальләре белән бүләкләнүче меңнәрчә, ун меңнәрчә алдынгылар—партияле һәм партиясез большевиклар моның ачык мисале булып торалар.

Дәүләтнең ягни халыкның гомуми интереслары аерым кешеләрнең интересларына караганда югары торганлыгын, аерым кешеләрнең интереслары дәүләт интересларына буйсынырга тиешлеген илебезнең хезмәт ияләренең абсолют күпчелеге яхшы аңлый. Җәмгыят милкен саклауда геройлык күрсәтү фактларын, халык интересы өчен җанын да аямау фактларын без көндәлек тормышта бик күп очратабыз. Бу, безнең илебездә социалистик стройның җиңүе нәтиҗәсе, хезмәт ияләре арасында коммунистик тәрбия эшен киң җәелдерү нәтиҗәсе булып тора.

Ләкин бу әле Советлар Союзында барлык хезмәт ияләре дә алдынгы кешеләр, коммунизм җәмгыятенең аңлы һәм актив төзүчеләр булып әверелде дигән сүз түгел. Эшчеләр, крестьяннар һәм хезмәткәрләр арасында дәүләткә азрак бирергә, ә үзләренә дәүләттән күбрәк йолкырга омтылучылар бар әле. Производствоны таркатырга тырышучылар, дәүләткә зиан китерүчеләр, хезмәт дисциплинасын бозучылар, ялкаулар, прогулчылар, летуннар, комсызлар да бар әле. Җәмгыят милкенә чит күз белән караучылар, „үгез үлсә ит, арба ватылса утын“ дип йөрүчеләр дә юк түгел әле. Билгеле, без мондый нәрсәләргә каршы кискен көрәш алып барырга тиешбез. Хезмәт дисциплинасын ныгыту өчен, социалистик милекне саклау өчен көрәш көндәлек тәрбия эше белән бик нык бәйләп алып барылырга тиеш.

Хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүдә, аларның аңында капитализм калдыкларын бетерүдә дингә каршы көрәшнең әһәмияте гаят зур. Вак буржуаз гадәтләрнең яшәүчән булуларын истән чыгарырга ярамый. Кешеләр үткәндәге таплардан, гасырлар буена капиталистик строй тудырган таплардан тиз генә арына алмыйлар. Хезмәт ияләре арасында коммунистик тәрбия эшен түземлелек белән, системалы рәвештә, көндәлек эшкә бәйләп алып барырга тиешбез. Без моны никадәр уңышлы үткәрсәк, коммунизмның тулы тантанасына шул кадәр тизрәк ирешербез.

Коммунистик тәрбия эшен уңышлы үткәрү өчен бездә барлык шартлар да бар. „Хәзер безнең дәүләтнең ил эчендә төп бурычы—хуҗалык-оештыру һәм культура-тәрбия буенча тыныч эштән гыйбарәт“ **(Сталин).**

Партия, совет, комсомол, профсоюз оешмаларының киң күләмдәге политик-массовый эшләре, большевистик матбугат, матур әдәбият, сәнгатнең барлык төрләре, кино, радио—болар барсы да хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүдә, кешеләрнең аңында капитализм калдыкларына каршы көрәшүдә гаят зур чаралар, көчле корал булып торалар. Без боларның барсыннан да тулысынча файдаланырга тиешбез.

Партиябезнең тарихи XVIII нче съезды тарафыннан, бөек Сталин тарафыннан куелган бурычларны тизрәк һәм уңышлы үтәүдә, коммунизмның җиңүен тизләтүдә хезмәт ияләренә коммунистик тәрбия бирү хәл иткеч әһәмият ала. „...Хәзер эш бары тик эшчеләрнең, крестьяннарнең, интеллигенциянең коммунистик аңлылыгы үсүдә генә. Калган барлык бурычларны хәл итү—киң магнәсендә коммунистик тәрбия бирүнең, хезмәт ияләренең бөтен массасын һәм бөтен совет интеллигенциясен чолгап алган коммунистик тәрбия бирүнең уңышларына, барыннан да элек, безнең бу өлкәдәге уңышларыбызга бәйләнгән“. **(Молотов).** Бурыч—коммунистик тәрбия эшен тагын да киңрәк җәелдерүдән, аның сыйфатын югары дәрәҗәгә күтәрүдән гыйбарәт.

## Чит илләрдә
## КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 12 февраль. Гавас агентлыгының хәбәр итүенә караганда, яңадан салкыннар башланганлыктан көнбатыш фронтта бер кадәр тынлык сизелә. Авиациянең активлыгы һаман да зур түгел. Германиянең бер самолеты Франциянең төньяк-көнчыгыш өлешендә очкан. Фронт арасындагы полосада патрульләрнең һәм разведка отрядларының хәрәкәте дәвам итә. Рейн елгасы буенда Германия ягыннан көчле атыш башланган.

БРЮССЕЛЬ, 12 февраль. „Журналь“ газетасының кичәге хәрби күзәтүендә болай диелә: „Нидада дошман безнең постларның берсенә һөҗүм итәргә маташты, ләкин автомат коралдан атып немецләрнең хәрәкәте туктатылды. Бәрелеш нәтиҗәсендә дошман үтерелгән кешеләрен калдырып чигенде. Үткән көннәрдәге кебек үк, безнең разведка Зигфрид линиясендә дошман урнашкан алгы позицияләргә үтеп керергә маташты. Бу разведканың бер патруле Вогезлар районында ныклы каршылык күрсәтүгә очрады һәм чигенергә мәҗбүр булды. Саар районында безнең икенче бер отряд белән немецләр арасында ныклы бәрелеш булды. Нәтиҗәдә без 10 кешене, ә немецләр 15 кешеләрен югалттылар“.

ЛОНДОН, 12 февраль. Рейтер агентлыгы тапшыра: „Кичә Германия самолеты Англия ярлары янында 371 тонна авырлыгындагы „Бостон трейдер“ пароходына бомба ташларга маташты, ләкин уңышсыз чыкты. Самолет 14 бомба ташлады һәм пулеметтан атты. Бомбалар барсы да пароход янына төштеләр. Пароход бортында 3 кеше җиңелчә яраланды“.

Шул ук вакытта, Норвегиянең нефть төяп Мексикадан Голландиягә баручы „Галлиа“ танкерының минага бәрелүе һәм җидди төстә зарарлануы хәбәр ителә.

БЕРЛИН, 12 февраль. Германия информация бюросы үткән атнада Грециянең 5.085 тонна авырлыгындагы „Керамиаи“ пароходының батканлыгын хәбәр итә. Экипаждан 28 кеше икенче бер карабка алынганнар.

(ТАСС).

## АК ФИННӘРГӘ ЯРДӘМ ИТҮГӘ КАРШЫ

ОСЛО, 11 февраль. (ТАСС). „Арбейдерен“ нын хәбәр итүенә караганда, Норвегия реакционерлары ак финнәргә „хезмәт ярдәме“ оештырырга маташалар. Алар Маннергейм армиясенә көчләп алыначак финнәргә алмашка ак Финляндиягә Скандинавия эшчеләрен җибәрергә телиләр.

Үзенең төньяк „туганнарыннан“ ярдәм сорап, Норвегиягә ак финнәрнең махсус агенты Лухокии килгән. Хәрби хезмәткә алынырга тиешле кешеләр, вербовка шартлары буенча, китү өчен үзләренең командованиеләреннән рөхсәт алырга тиешләр. Ләкин, Норвегия социал демократ лидерларының фикренчә, бу хәл „доброволецлар“ җибәрүгә тоткарлык ясый алмаячак.

Норвегиянең эре промышленниклары да профбюрократлар белән бергә эш итәләр. Алар үз предприятиеләрендә эшләүче эшчеләрне ак Финляндиягә китәргә мәҗбүр итү өчен басым ясауда барлык чаралардан файдаланалар. Эшсезләрне югары хезмәт хакы вагдә итү белән кызыктыралар.

Профсоюз лидерларының хиянәт итүләренә ачулары килеп, Шиен шәһәренең тегермән эшчеләре илдә котырынган төстә алып барыла торган сугыш пропагандасына каршы кискен протест белдереп резолюция кабул иттеләр. Резолюциядә болай диелә: „Без ак Финляндиягә доброволецлар туплау өчен агитация алып баруны туктатуны нык таләп итәбез. Норвегия үз территориясе аркылы корал һәм чит ил гаскәрләре үткәрергә рөхсәт итмәскә тиеш“.

Тронгейм шәһәренең балта осталары һәм столярлар союзы да шундый ук резолюция кабул итте.

НЬЮ-ЙОРК, 11 февраль. (ТАСС). „Дейли Уоркер“ нын хәбәр итүенә караганда, Һиндстан милли конгрессының элекке председателе Неру, СССР белән Финляндия арасындагы мөнәсәбәтләргә кагылып, болай дигән: „Советлар Союзына Финляндия аркылы интервенция хәзерләнгәнлеккә һич шик юк. Ленинград Финляндия чигеннән бары берничә миль ераклыкта гына урнашкан һәм Финляндиядә нинди сугыш планнары хәзерләнү һәр кемгә маглүм“.

НЬЮ-ЙОРК, 11 февраль. (ТАСС). „Дейли Уоркер“ нын хәбәр итүенә караганда, Массачузетс штатындагы Уорсестер шәһәренең „Скандинавия эшчеләренең культура җәмгыяте“ Америка сенатыннан ак Финляндиягә финанс ярдәме күрсәтүне туктатуны таләп иткән.

## Литвада Англия—Франция блогының казыну эше турында Германия газетасы

БЕРЛИН, 12 февраль. (ТАСС). „Рейнишвестфалише цейтунг“ газетасы Вильнодан алынган түбәндәге хәбәрне иглан итә: „Көнбатыш державалар күп кенә еллар буена Европада сугыш уты кабызу өчен Вильно мәсьәләсеннән файдаланырга омтылдылар. Үткән елның октябрендә Вильно шәһәре Литвага кайтарып бирелде. Моннан 20 ел элек үк инде бу шәһәрне Польшаның басып алуын яхшы дип тапкан Англиягә һәм Франциягә бу ошамады. Соңгы вакытта Англия һәм Франция Вильнога үзләренең агентларын җибәрделәр. Алар шунда күп санда булган поляк качакларын үз теләкләре өчен файдаландылар. Мятежчылар ядросы Вильнодагы поляклар университеты студентларыннан һәм укытучыларыннан торды. Дошманлык кабызу өчен поляк поплары да мөмкин булганның бөтенесен эшләделәр. Литва полициясе бу заговорларны вактында бетерде. „Полякларга начар караштa“ булуны сылтау итеп, шушы уңай белән Англия һәм Франция белдергән протест—бу державаларның Литваның эчке эшләренә катнашулары дигән сүз. Англиянең һәм Франциянең котырту хәрәкәтләренә каршы протест белдерергә Литва хөкүмәтенең бөтен нигезләре бар иде. Литва халкы үз эшенә көнбатыштагы державаларның катнашуын кискен төстә кире кага. Литваның үз политикасына ышанычы Советлар Союзы белән һәм Германия белән дусларча мөнәсәбәттә булуына нигезләнә“.

## „ДЕЙЛИ ГЕРАЛЬД“ РЕДАКТОРЫНЫҢ УРЫННАН АЛЫНУЫ

ЛОНДОН, 11 февраль. (ТАСС). Лейбористлар газетасы „Дейли Геральд“нын редакторы Френсис Уильямс шушы атнада кинәт эшеннән алынган. Аның урыннан алынуы газета хуҗаларының ризасызлыгыннан килеп чыккан дип хәбәр итәләр. Газета хуҗалары Уильямсның позициясен „артык куркынычлы“ дип санаганнар. („Дейли Геральд“ „Одхэмс Пресс“ газета трестының, профсоюзлар генсоветының һәм лейбористлар партиясе башкарма комитетының органы).

Уильямс, Англия һәм Франция тарафыннан башланган империалистик сугышны яклап „Дейли Геральд“ газетасының редакция коллегиясендә, партиянең рядовой членнарының ышанычын саклап калу теләге белән, Англия хөкүмәтенең позициясенә карата газетаның беркадәр оппозициядәрәк торуын яклаган булган.

„Дейли Геральд“нын редакторы итеп бер вакытны лорд Бивербрук трестының „Ивнинг стандард“ газетасында редактор булган Перси Кудлипп билгеләнгән.

## ХРОНИКА

■ РСФСР Верховный Советы Президиумының шушы елның 9 нчы февраль карары буенча иптәш Г. В. Козлов РСФСР Верховный Советы Президиумы секретарьлыгы хезмәтләреннән азат ителде һәм аңа дәвалану өчен ял бирелде.

■ ССР Союзы Совнаркомы иптәш С. И. Алюшинны элемтә халык комиссарының урынбасары итеп билгеләде һәм аны Элемтә Наркоматы коллегиясе составына кертте.

(ТАСС).

**Фин ак гвардеецларына каршы сугышларда катнашучы Советлар Союзы Герое кече лейтенант К. С. Симонян.**

М. Редкин фотосы (ТАСС фотоклишесе).

## Германия белән СССР арасында хуҗалык килешүе төзелү турында белдерү

Шушы елның 11 нче февралендә Москвада, уңышлы тәмам булган сөйләшүләрдән соң, ССР Союзы белән Германия арасында хуҗалык килешүе төзелде. Бу килешү Германия белән СССР арасында товар әйләнеше буенча экономик программа эшләү турында ике ил хөкүмәтләренең теләкләренә җавап бирә. Бу теләкләр 1939 нчы елның 28 нче сентябрендә СССР нын Халык Комиссарлары Советы Председателе һәм Чит Ил Эшләре Халык Комиссары иптәш В. М. Молотов белән Германиянең Чит Ил Эшләре Министре Фон-Риббентроп әфәнде арасында алышкан хатларда күрсәтелгән иде.

Хуҗалык килешүе СССР дан Германиягә чимал чыгаруны һәм аңа алмашка Германиядән СССР га промышленность нәрсәләре кертүне күздә тота.

Килешү гамәлгә кертелүнең беренче елында ук инде Германия белән СССР арасында товар алмашу бөтен дөнья сугышыннан соң кайчан булса да ирешелгән иң зур күләмне артып китәчәк.

Киләчәктә ике ил арасында товар алмашуны тагын да арттыру күздә тотыла.

СССР ягыннан килешүгә СССР нын Тышкы Сәүдә Халык Комиссары иптәш А. И. Микоян һәм СССР нын Германиядәге сәүдә вәкиле иптәш Е. И. Бабарин, ә Германия ягыннан—Германия хөкүмәтенең экономик мәсьәләләр буенча махсус вәкиле Риттер әфәнде һәм Германиянең экономик делегациясе председателе Шнурре әфәнде кул куйдылар.

## КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

### КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Авиация һәм көчле артиллерия уты ярдәме белән япон гаскәрләренең 3 меңләп кешедән торган колоннасы Биньяннан Литанга (Линьбиннән 40 километр көнчыгыштарак) һөҗүм башлады. Япон гаскәрләренең сул флангы Наньниннан төньяк юнәлештә, шоссе юлы буйлап Уминга таба хәрәкәт итүендә дәвам итә. Сугышлар Уминнан көньяктарак Шуанцияю тирәсендә бара. Монда хәрәкәт иткән япон гаскәрләренең бер өлеше үзләренең Биньян районында тупланган төп көчләре белән кушылу өчен Уминнан көнчыгыш юнәлештә хәрәкәт итә башлады.

Кытай гаскәрләренең баш командованиесе японнарга отпор бирү өчен монда шактый көчләр туплый.

### ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Суйюань провинциясендә соңгы 10 көн эчендә японнарның 3 мең кешесе үтерелгән һәм яраланган.

Шул ук вакытта кытайлар японнарның 70 ләп автомашиналарын һәм танкларын сафтан чыгарганнар.

### ҮЗӘК КЫТАЙДА

Японнар Сяошань тирәләрендә оборона корылмалары ясыйлар. Алар бу тимер юл узелын кулларында нык тотарга уйлыйлар булса кирәк. Японнар авиациясе Чжэцзян провинциясенең көнбатыш өлешендә аерым пунктларны бомбага тота. 8 нче февральдә японнарның 9 самолеты Чжусяньне, Лишуйны һәм башка пунктларны бомбага тотты.

Анхуэй провинциясендә кытайлар артиллериясе Янцзы елгасыннан югарыга таба менеп баручы японнар транспортына атып аңа зур зиян китерде.

⁂

„Даваньбао“ газетасы Сеошаньнан төньяк-көнбатыштарак курчак хөкүмәт гаскәрләре отрядының кытайлар ягына чыкканлыгын хәбәр итә.

## ПАРИЖДА БУЛГАН ПОЛИЦИЯ ҺӨҖҮМЕ ТУРЫНДА БОЛГАРИЯ МАТБУГАТЫ

СОФИЯ, 11 февраль. (ТАСС). Болгария матбугаты Парижда совет учреждениеләренә полициянең һөҗүме турында тулы хәбәрләр урнаштыра. „Париж полициясе дипломатия традицияләрен таптады“ дигән мәкаләсендә „Заря“ газетасы полиция һөҗүменең сәбәпләрен рәсми төстә аңлатулар булуга да карамастан, „Объектив политик даирәләрдә бу акт полиция тарафыннан тупас көчләү күрсәтү һәм дипломатия традицияләрен бозу дип карала“ дип яза.

## ФРАНЦИЯ АРМИЯСЕНДӘ ДЕЗЕРТИРЛЫК

РИМ, 10 февраль. (ТАСС). Стефани агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Франция хөкүмәте хәрби хезмәттән качып калуларга каршы рәхимсез көрәш алып бара. Рәсми маглүматларга караганда, сугыш башланганнан алып, шушы елның 31 нче январена кадәр армиядә хезмәт итүдән законсыз төстә азат ителгән 13.000 хәрби хезмәткәр үзләренең фронттагы частьләренә кире җибәрелгәннәр. Болардан тыш хәрби трибуналлар фронттан качучыларга каршы 20 процесс кузгатканнар.

## „СТАЛИН ХУДОЖЕСТВО ӘДӘБИЯТЫНДА“ ДИГӘН КҮРГӘЗМӘ

Дәүләт әдәбият музеендә „Сталин художество әдәбиятында“ дигән күргәзмә ачылганга бүген бер ай тула. Иптәш Сталинның 60 еллыгына карата оештырылган бу күргәзмә гаят зур уңыш белән файдалана. Монда Союзның төрле шәһәрләреннән язучылар, студентлар, фәнни работниклар, укытучылар, экскурсантлар булалар.

Күргәзмә яңа экспонатлар белән тулыландырылды. Шушы көннәрдә генә Ленинград художество академиясен тәмам иткән яш художник А. П. Шепелюкның—„И. В. Сталин, В. М. Молотов һәм К. Е. Ворошилов 1936 нчы елның июнендә авыручы М. Горький янында“ дигән акварели алынды, ул гаят зур игтибарны үзенә тарта.

(ТАСС).

## ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

11 нче февральдә фронтта разведчикларның эзләнүләре, ә кайбер урыннарда артиллериядән атышу булды. Ладога күленнән төньякта кечкенә пехота частьләренең бәрелешләре дәвам итте. Карелия бугазында артиллериядән атышу һәм пехота частьләренең бәрелешүе булды. Нәтиҗәдә дошман алып ташланды һәм безнең алдынгы частьләребез ныгытылган 16 оборона пунктын алдылар. Бу пунктларның 8 е—тимер бетоннан ясалган артиллерия корылмалары.

Безнең авиация разведка һәм сугыш очышлары ясады.

12 нче февральдә фронтта разведчикларның эзләнүләре һәм берничә районда пехота частьләренең һәм артиллериянең җанлы хәрәкәтләре булды.

Карелия бугазында безнең гаскәрләр уңышлы хәрәкәт итеп, ныгытылган 32 оборона пунктын алдылар. Аларның 12 се—тимер бетоннан ясалган артиллерия корылмалары.

Соңгы 3 көн эчендә без алган ныгытылган пунктлар районнарында дошманның югалтулары—230 пулемет һәм 82 орудие.

Һава начар булганлыктан авиациянең хәрәкәте разведка очышлары белән генә чикләнде.

# ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

## ЗАВОД КОММУНИСТЛАРЫ АЛДЫНГЫ САФЛАРДА

Серго исемендәге заводта, турыдан-туры производствода эшләүче коммунистларның инициативасы буенча, стахановчылык хәрәкәтенең яңа формасы—берьюлы берничә станокта эшләү һәм берничә профессияне үзләштерү киң җәелдерелә.

Хәзер заводта берьюлы берничә станокта эшләүче 123 кеше бар, алар 330 станокка хезмәт күрсәтәләр. Эшчеләрдән һәм хезмәткәрләрдән 139 кеше икешәр һәм өчәр профессия эшен башкара. Коммунистлардан Лысов һәм Павлов иптәшләр өчәр пичтә эшләүгә күчтеләр. Бу аларга хезмәт җитештерүчәнлеген бермә-бер арттыру һәм продукциянең сыйфатын яхшырту мөмкинлеген бирде. Цех һәм участкы начальникларыннан коммунист Блохин, Кузьмин, Орловцев, Афанасьев һәм башка иптәшләр күп станокларда эшләү методын куллануны җәелдерү буенча зур эш алып баралар.

Заводта коммунист иптәш Шамиевның башлап җибәрүе буенча, 138 урында стахановчылар мәктәпләре оештырылды. Быелның январь аенда бу мәктәпләрдә йөзләрчә эшчеләр укытып чыгарылды.

Коммунистлар производствоны рационаллаштыру эшенә актив катнашалар. Коммунист инженерлардан Давышев, Скороходов, Мартынов һәм башка иптәшләр заводның бер цехын реконструкцияләү турында тәкъдим керттеләр. Партоешма бу чараны тормышка ашыруга ирешә. Хәзер цех продукцияне бермә-бер арттырып бирә, брак ясау 20 процентка кимеде. Инженер иптәш Семенистов кертигән тәкъдим заводка зур экономия бирә. Тиздән завод иптәш Семенистов методы буенча эшләргә хәзерләнә. Узган елны заводта рационаллаштыру буенча 70 тәкъдим тормышка ашырылды.

Завод коллективы ярты еллык планны Татарстан АССР ның 20 еллыгына, ә еллык планны 24 нче декабрьгә—хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлауларның беренче еллыгы көненә үтәргә йөкләмә алды. Хезмәтнең җитештерүчәнлеген 25 процент күтәрү, бракны үткән елга караганда 50 процент киметү һ. б. турында йөкләмәләр алынды.

*В. Шульгин.*

Серго исемендәге заводның партбюро секретаре.

## ДИНГӘ КАРШЫ ПРОПАГАНДА ЭШЕ КӨЧӘЯ

1939 нчы елны дингә каршы пропаганда эшен яхшырту теләге белән, Сугышчан Алласызлар Союзының Әтнә район советы, 16 ячейка һәм 22 укытучы конкрет йөкләмәләр алып, Бөтенсоюз социалистик ярышына кушылганнар иде. Алар алган йөкләмәләрен үтәү өчен хезмәт ияләре массасы арасында системалы рәвештә дингә каршы пропаганда алып бардылар. Дин башлыкларының—муллаларның реакцион йөзләрен фаш итүдә якыннан катнашучылар булып әвереләләр.

1939 нчы ел ахрына районда Сугышчан Алласызлар Союзының 60 ячейкасы оештырылды һәм члennар саны 1.650 кешегә җитте. Укытучылар һәм врачлар хезмәт ияләре массасы арасында дингә каршы темада 200 гә якын лекцияләр укыдылар һәм доклад ясадылар. 254 тапкыр беседа һәм кычкырып укулар үткәрелде. Радио аркылы 19 лекция тапшырылды. Беседаларга, докладларга һәм кычкырып укуларга 17 меңгә якын кеше катнашты.

Алласызлар Союзының район советы дингә каршы пропаганда алып бару өчен агитаторлар хәзерләү теләге белән, 5 көнлек курслар үткәрде, аларда 23 кеше укып чыкты. Курста укыган иптәшләр сайлауларга хәзерлек вакытында актив эш алып бардылар.

Бу өлкәдә Г. Фәезев, С. Шагалиев һәм Маннапов иптәшләр аеруча яхшы эшләделәр. Иптәш Фәезев 5 колхозда Сугышчан Алласызлар Союзы ячейкалары оештырды, колхозчылар өчен 12 һәм мәктәп балалары өчен 5 лекция укыды, дингә ышанучылар арасында индивидуаль беседалар алып барды. Иптәш Шагалиев Киров исемендәге колхозның уку өендә һәм терлекчелек фермасында колхозчылар һәм колхозчы хатын-кызлар арасында дингә каршы пропаганда алып барды.

Сугышчан Алласызлар Союзының члены Маннапов (Олы Әтнә авылы) дингә каршы пропаганда эше алып баруда аеруча яхшы эшли. Ул диннәрнең ялганлыгы һәм зарарлы икәнлеге турында беседалар үткәрде һәм район газетасында аның ике мәкаләсе басылып чыкты.

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлауларга хәзерлек уңае белән, Сугышчан Алласызлар Союзы члennарыннан 200 дән артык агитатор дингә каршы пропаганда алып барды. Тәрбия эшен киң җәелдерү нәтиҗәсендә, дини-гореф гадәтләрне үтәү фактлары көннән-көн кими. Хезмәт ияләре динчеләрнең кабахәтлекләрен фаш итәләр. Сугышчан Алласызлар Союзының карт члены Гариф иптәш Мортазин (К. Киме авылы) болай ди:

— Мин революциягә кадәр 5 ел көтү көттем. Ярлы булдык. Шуңа күрә укып булмады. Мулла мине берничә тапкыр кыйнады. Октябрь революциясе минем кебек миллионнарга бәхетле тормыш алып килде, балаларым барсы да мәктәптә укыйлар. Инде үзем дә укырга һәм язарга өйрәндем.

Иптәш Сабирова болай ди:

— Мин муллада эшләп тордым. Шул вакытта ук муллаларның ураза тотмауларын белдем. Мулла белән абстай һәр көн бикләнеп чәй эчәләр иде. Ә миңа: „Син ярлы кеше. Хәерсәдака бирә алмыйсың. Синең өчен ураза тоту мәҗбүри“ дип ураза тоттыралар иде.

Әтнә районында революциягә кадәр 60 мәчет, берничә чиркәү бар иде. Хәзер аларның күбесе культура йортларына әйләнделәр.

Ләкин барлык авылларда да дингә каршы пропаганда яхшы куелган дип әйтеп булмый әле. К. Киме, Олы Бәрәзә, Олы Мәңгәр, Түбән Бәрәскә һәм Югары Сәрдә авылларында партия һәм комсомол оешмалары дингә каршы пропаганда эшенә җитәкчелек итмиләр.

*С. Хөсәенова.*
*М. Кузяев.*

Икенче мех фабрикасының слесаре иптәш А. С. Михеев үзенең өйрәнчегенә, отделка цехының стахановчысына, машина частьләрен өйрәтә.

А. Усольцев фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

## КОММУНИСТЛАРНЫҢ РАЙОН ҖЫЕЛЫШЫ

Чепья районында коммунистларның район җыелышы үткәрелде. Җыелыш 1939 нчы елда партиянең район оешмасы буенча ВКП(б) га кабул итүнең йомгаклары турындагы һәм 1940 нчы елның язгы чәчүенә хәзерлек турындагы мәсьәләне тикшерде.

Көн тәртибендәге беренче мәсьәлә буенча фикер алышулар бик җанлы барды. Иптәш Юсупов үзенең чыгышында болай диде:

— Райком яшь коммунистлар арасында эшләүгә җидди игтибар бирми. Партиянең күп кенә башлангыч оешмалары партиягә яңа кабул ителгән иптәшләргә партпоручениеләр бирсәләр дә, аларның үтәлешен тикшермиләр. ВКП(б) райкомы инструкторлары күп вакытта хуҗалык кампанияләре белән шөгыльләнеп, үзләренең төп бурычларын онытолар. Яшь коммунистларның район җыелышлары бик сирәк үткәрелә.

Чыгып сөйләүчеләрдән иптәш Әхметшин районда алдынгы хатын-кызларны, колхозчыларны партия сафларына тарту эшенең начар торуы турында сөйләде. 1939 нчы елда хатын-кызлардан ВКП(б) члены итеп 3 кенә кеше кабул ителгән.

Икенче мәсьәлә буенча сөйләүче иптәшләр районда язгы чәчүгә хәзерлек эшенең канәгатьләнерлек алып барылмавын күрсәтеп үттеләр. Кышкы агротехника чараларын үткәрү эше аеруча начар тора. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау да бик акрын бара.

Коммунистларның район җыелышы ВКП(б) Өлкә Комитетының VIII нче пленумы карарларын бердәм рәвештә яхшы дип тапты һәм аларны тормышка ашыру өчен практик чаралар билгеләде.

*Х. Галләмев.*

## ПЛЕНУМ ЧЛЕННАРЫНЫҢ РАЙКОМГА БУЛЫШЛЫГЫ

Азнакай райкомының пленум составы 13 кешедән тора. Эштә ярдәм күрсәтү өчен, алар барсы да, аерым башлангыч партоешмаларга беркетелгәннәр. Райкомның һәр пленумында бу иптәшләрнең эш планнары раслана һәм элеккеге пленумда расланган планнарның ничек үтәлүләре турында информацияләр тыңлана. Шулай эшләү нәтиҗәсендә, пленум члennарының күбесе райкомның көндәлек эшенә актив катнашалар һәм үзләре беркетелгән башлангыч оешмаларга зур булышлык күрсәтәләр. Мәсәлән, 1939 нчы елның соңгы ике аенда гына да, пленум члennары, төрле мәсьәләләр буенча, райондагы 142 коммунист белән сөйләштеләр.

Райком члены иптәш Ганиев „Мәллә“, „8 нче Март“ һәм „Берек“ колхозлары янындагы башлангыч партоешмаларга беркетелгән. Ул, хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына булып үткән сайлау кампаниясе чорында агитация-масса эшләрен яхшыртуда бу оешмаларга зур ярдәм күрсәтте.

Иптәш Нәҗипов „Сарсаз“ колхозы, май заводы, МТС һәм Райпотребсоюз партоешмаларына партҗыелышларның протоколларын рәсмиләштерү һәм партия хуҗалыгын юлга салу мәсьәләсендә яхшы гына ярдәм итте. Шулай ук ул, теоретик белемнәрен күтәрү өстендә коммунистларның ничек эшләүләре белән танышу өчен, бу оешмадагы 36 коммунист белән беседа үткәрде.

Райком члennарыннан Хуҗин, Лотфуллин һәм Хәбибуллин иптәшләр дә үзләренә бирелгән поручениеләрне вактында үтиләр. Һәм эштә райкомга якыннан торып ярдәм итәләр.

Ләкин райкомның кайбер члennары райком эшенә якыннан катнашмыйлар әле. Мәсәлән, Җәләев, Маннапов һәм Ислаев иптәшләр бирелгән поручениеләрне үтәмиләр, райком члennарының бурычы пленумга катнашудан гыйбарәт дип кенә уйлыйлар. ВКП(б) райкомы да бу иптәшләрдән эш таләп итүдә йомшаклык күрсәтә.

*Г. Исламов, Х. Закиров.*

## БЕР КЕШЕГӘ 12 ПАРТПОРУЧЕНИЕ

Әтнә районы, Яңа Җөлби авылы башлангыч мәктәп мөдире иптәш Камил Гарифҗанов, партиябезнең XVIII нче съездыннан соң ВКП(б) членлыгына кандидат итеп кабул ителде. Ул тиз вакыт эчендә оештыручы-массовик булып үсте. Җәмәгать эшләрен зур активлык белән башкара. Иптәш Гарифҗанов авыл советына депутат итеп сайланды. Комсорг булып эшли. Агитколлективка җитәкчелек итә. Колхозда агротехника түгәрәгенә җитәкче итеп билгеләнде һ. б. Яңа ВКП(б) райкомы һәм Яңа Җөлби авылындагы кандидатлар группасы тарафыннан барлыгы 12 поручение бирелгән. Шулай итеп, ул поручениеләр белән чолганып алынган. Билгеле, бу нормаль хәл түгел.

Поручениеләрнең чиктән тыш күп йөкләнүе, аның төп эшенә гаять нык комачаулык иткән. Соңгы вакытта аның мәктәбендә күрсәткечләр түбәнәйде. Бу мәктәптә укучыларның дәрескә йөреше беренче чиректә 98,3 процент булса, икенче чиректә 95,3 кенә процент булуын күрәбез. Өлгереш буенча да шундый ук хәл. Беренче чиректә укучыларның өлгереше 88,8 процент булса, икенче чиректә ул 84,8 процентка төште. Балалар арасында массавый тәрбия эшенең торышы да канәгатьләнерлек түгел. Мәктәптә пионерлар саны үсми. Социалистик ярыш тиешенчә җәелдерелмәгән. Ярыш договорларының үтәлеше тикшерелми. Балалар арасында газета-журналлар бик аз санда алдырыла.

ВКП(б) райкомы һәм кандидатлар группасы бу нормаль булмаган хәлгә чик куярга тиешләр. Партпоручениеләр нормаль булырга һәм алар коммунистларның төп эшләренә комачаулык китермәскә тиеш.

*С. Мостафин.*

*Матбугат күзәту*

## Массовый-оборона эшен игтибар үзәгенә

Капиталистик чолганыш турындагы мәсьәләне СССР халыклары бер минутка да исләреннән чыгармыйлар. Миллионлаган совет патриотлары зур энтузиазм белән, хәрби эшне өйрәнәләр: ату отличниклары, пулеметчиклар, граната ыргытучылар, танкистлар, очучылар булырга омтылалар.

Бурыч—хезмәт ияләре арасында политик-тәрбия эшләрен тагын да яхшыртудан һәм шул нигездә, массовый оборона оешмаларының тагын да яхшырак эшләүләренә ирешүдән гыйбарәт. Моның өчен, иң беренче чиратта, Массовый оборона оешмаларын булдыклы кадрлар белән ныгытырга һәм аларга көндәлек эшләрендә даими булышлык күрсәтергә кирәк.

Кызганычка каршы, кайбер район газеталары һәм күп тиражлы газеталар бу өлкәдә үз рольләрен аңлап җиткермиләр, оборона мәсьәләләрен газета битләрендә яктыртуга җитәрлек игтибар бирмиләр.

Мәсәлән, **Кызыл Йолдыз** район газетасы (редакторы иптәш Кәрәмов) оборона темасына быел бары 2 материал урнаштырган: ике район допризывникларының социалистик ярыш договоры һәм кыска сигналлар рубрикасында кечкенә бер хәбәр.

„Правда“ колхозында осоавиахим оешмасы председателе иптәш Димитриев оешма белән бер төрле дә җитәкчелек итми. Осоавиахим члennары арасында сугыш белемен өйрәтү оештырылмаган... Оешманың эшен яхшыртуда район осоавиахим советы практик ярдәм күрсәтергә тиеш“ (18 январь).

Кызыл Йолдыз район газетасының айдан артык вакыт эчендә осоавиахим оешмаларына күрсәткән „хезмәте“ әнә шундый бердәнбер хәбәр белән чикләнә.

Күп тиражлы газеталарга күз салыйк.

Казан предприятиеләренең, шулай ук районнардагы предприятиеләрнең һәр кайсында Осоавиахим, РОКК оешмалары бар. Бу оешмаларның эшләрендә зур кимчелекләр яшәп килә һәм аларга, һич шиксез, булышлык кирәк. Ләкин предприятиеләрдә чыга торган кайбер газеталар бу тармакны истән чыгаралар. Мәсәлән, **„Удар темп өчен“** (Киез итекфетр фабрикасы), **„Вахитовчы“** (жиркомбинат), **„Большевичка“** (Тегү фабрикалары) газеталары оборона темасына январь аенда бары тик берәр материал урнаштырганнар. **„Кызыл тукучы“** (Кукмара), **„Отличник“** (Серго исемендәге завод) газеталары оборона темасына бөтенләй язмыйлар. **„Бондюг эшчесе“** газетасы да шулай ук, значкистлар санының артуы, Бөтенсоюз чаңгы кроссына Бондюг заводының да катнашуы турында берничә юллык информация белән чикләнгән.

Иптәш Сталин оборона эшенә зур әһәмият биреп, болай ди:

**„Сугыш һөҗүме куркынычы каршында безнең бөтен халкыбызны мобилизацион хәзерлек хәлендә тотарга кирәк, бер нинди дә „очраклылык“ һәм безнең тышкы дошманнарыбызның бер нинди дә фокуслары безне көтелмәгән хәл алдында калдырырлык булмасын...“**

Массовый оборона оешмаларының эшләре иптәш Сталинның менә шушы күрсәтмәләрен тулысынча үтәрлек итеп оештырылырга тиеш һәм бу күрсәтмәләр газета работниклары өчен дә эш программасы булып тора.

Без карап чыккан газеталардан уңышлы яклары белән Чаллы һәм Буа район газеталары аерылып торалар. Бу газеталар оборона темасына еш кына һәм яхшы эчтәлекле материаллар бирәләр, кызыл армеецлар белән элемтә тоталар һәм аларның хатларын газета аша массага җиткерәләр.

Мәсәлән, **„Яңа юл“** (Буа) газетасы үзенең баш мәкаләсендә (28 январь) районда оборона эшенең торышын, уңышлы һәм җитешсез якларны тулы чагылдырып, кызыклы фактлар китерә. Вахитов исемендәге урта мәктәптә 175, педучилищедә 190 осоавиахим члены бар. Осоавиахимның 20 урында яңа оешмасы төзелгән. Осоавиахимның „Кәрәш“ колхозы янындагы оешмасы соңгы көннәрдә 26 ПВХО значкисты, 15 Ворошиловча атучы, „Красное пламя“ колхозындагы оешма—16 ПВХО һәм 12 Ворошиловча атучы значкисты хәзерләгән. РОКК ның „Кызыл йолдыз“ колхозы янындагы оешмасында 17 кеше ГСО значогына норма тапшырганнар

„Бу колхозларда массовый оборона оешмаларының эшләрен яхшыртуда партоешмалар һәм аерым коммунистлар практик ярдәм күрсәтәләр“.

Шуның белән бергә:

„... кайбер башлангыч партоешмалар оборона эшенә җитәкчелектә карарлар чыгару белән генә чикләнәләр... Райондагы коммунистларның 45 проценты гына осоавиахим члены булып торуы моны ачык күрсәтә“,—дип, газета кимчелекле якларны да ачып сала һәм партоешмаларның игтибарын кимчелекләрне бетерүгә юнәлтә.

Данлыклы Кызыл Армиянең XXII еллыгы якынлаша. Бу уңай белән, массаның политик һәм производство активлыгы тагын да үсте. Газеталар илебезнең оборонасын ныгыту буенча үзләренең бурычларын яхшы аңларга, хезмәт ияләренең активлыгын массовый оборона эшләрен тагын да яхшыртуга юнәлдерергә тиешләр.

# Производствода коммунистларның авангардлык роле

ВКП(б) ның XVIII нче съезды Сталинчыл өченче бишьеллыкта халык хуҗалыгы үсешенең бөек программасын кабул итеп, илебез алдына якындагы 10—15 ел эчендә төп капиталистик илләрне экономик яктан да куып җитү һәм узып китү бурычын куйды һәм аны үтәү юлларын билгеләде. Съезд карарлары коммунистларны һәм илебезнең барлык хезмәт ияләрен социалистик ярышны тагын да киңрәк җәелдерү өчен, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү өчен көрәшкә рухландырдылар.

Производствода коммунистларның авангардлык рольләре тагын да ныграк үсте. Алар хезмәткә социалистик карашны көчәйтүдә, хезмәт дисциплинасын ныгытуда, производство техникасын яхшы үзләштерүдә, производство заданиеләрен югары сыйфатлы итеп һәм арттырып үтәүдә инициатива һәм үрнәк күрсәтәләр.

Илебезнең һәм шул исәптән республикабызның күп кенә фабрикалары һәм заводлары 1939 нчы елның производство планнарын арттырып үтәделәр. Менә мех комбинаты. Аның беренче фабрикасы еллык планны 100,4 процент итеп, срогыннан алда үтәде. Һәм планнан тыш 800 мең сумлык продукция бирде. январь аеның планын 113 процент итеп үтәүгә ирешә. Стахановчылар арасыннан производство командирларының яңа армиясе үсеп чыкты. Стахановчы, ВКП(б) члены иптәш Крюков мезрилный бүлекнең начальнигы итеп күтәрелде. Аның җитәкчелегендә бу бүлекнең эшчеләре хезмәткә социалистик караш, дисциплиналык һәм инциатива үрнәкләре күрсәтәләр. ВКП(б) члennары Билаутдинов, Җәләлеттинов, Игнатьев һәм Емельянов иптәшләр көнлек нормаларын 180—200 процент итеп үтиләр.

Вахитов исемендәге жиркомбинатта производстводан аерылмыйча укып, инженер һәм техник булу дәрәҗәсенә ирешкән эшче коммунистлар күп. Алар комбинатның заводларында, участкыларында, цехларында һәм бүлекләрендә производство камандирлары булып күтәрелделәр. Мәсәлән, ВКП(б) члены иптәш Матвеев рядовой эшче иде. Ул техника белән бик кызыксынды һәм аны яхшы итеп үзләштерүдә зур тырышлык күрсәтте. Хәзер ул сабын заводының инженеры булып эшли. Иптәш Матвеев үзенә йөкләнгән җаваплы бурычны яхшы башкара, стахановчылык хәрәкәтен тагын да киңрәк җәелдерүдә зур ярдәм итә.

ВКП(б) члены иптәш Михайлов комбинатка гади эшче булып килгән иде. Ул, техниканы үзләштерүгә зур игтибар бирде, күп кенә профессияләрне, эшнең катлаулы процессларын өйрәнде. Хәзер ул стеарин заводының инженеры итеп күтәрелде. Иптәш Михайлов политик яктан да үсте, ул хәзер стеарин заводында башлангыч партоешма секретаре.

Эшче хатын-кызлардан ВКП(б) члены иптәш Зайчникова мастер дәрәҗәсенә, ВКП(б) членлыгына кандидат иптәш Ефремова техник дәрәҗәсенә күтәрелделәр.

Ләкин кайбер предприятиеләр янындагы партоешмалар, аерым коммунистлар дәүләт планын үтәүгә, производство мөмкинлекләреннән тулы файдалануга, стахановчылык хәрәкәтен җәелдерүгә һәм алдынгыларның эш тәҗрибәләрен башкаларга күчерүгә игтибар биреп җиткермиләр әле. „Спартак“ комбинаты бөтен мөмкинлекләре булуга карамастан, 1939 нчы елның производство планын үтәмәде. Планны үтәү өчен көрәш хәзер дә канәгатьләнерлек түгел. Партоешма предприятиедә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү һәм стахановчылык хәрәкәтен җәелдерү мәсьәләләре белән җитәрлек шөгыльләнми. Гармон фабрикасында эш тагын да начаррак тора. Биредә масса-анлату эше ныклы юлга куелмаган. Партоешма производствода коммунистларны дөрес урнаштыру, кадрларны өйрәнү мәсьәләләре белән конкрет рәвештә шөгыльләнми. Стахановчылык хәрәкәтенә оператив җитәкчелек итми.

Фабрика 1939 нчы елның производство планын 91,9 процент кына үтәгән. Менә бу фактлар гармон фабрикасы партоешмасының производствода эшне большевикларча оештыру өчен ныклы көрәш алып бармавы турында сөйлиләр.

Илебез алдында Сталинчыл өченче бишьеллык планны барлык тармаклар буенча большевикларча үтәү бурычы тора. Коммунистның үзенең генә үрнәк рәвештә эшләве җитми. Ул, производствода партиясез эшчеләрне, инженер-техник работникларны, хезмәткәрләрне дәүләт тарафыннан куелган бурычларны үтәү өчен көрәшкә тупларга, аларның үрнәк рәвештә эшләүләренә ирешергә тиеш.

Партоешмаларның бурычы—Сталинчыл Өченче Бишьеллык исемендәге социалистик ярышны киң җәелдерүгә җитәкчелек итүдән, коммунистларның һәм партиясез активистларның игтибарын хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү өчен көрәшкә туплаудан гыйбарәт.

## Оборона эшен зур кызыксыну белән өйрәнәләр

Кукмара районында массовый-оборона оешмалары туктаусыз үсә. Район буенча Осоавиахим сафларында 1.566 кеше член булып тора. Хезмәт ияләре хәрби эшне зур кызыксыну белән өйрәнәләр. Оборона значкистларының саны көннән-көн арта. 1939 нчы елны ворошиловча атучылар значегына 440 кеше, ПВХО значегына 740 кеше нормалар тапшырды.

Мәчкәрә, Поч. Күчүк авылларында һәм Кукмарадагы урта мәктәптә соңгы вакытларда оборона эшләре сизелерлек рәвештә яхшырды. Мәчкәрә авылында Осоавиахим оешмасында 121 кеше член булып тора. Шулардан ворошиловча атучылар значегына 45, ПВХО значегына 90 һәм ГСО значегына 50 кеше нормалар тапшырды. Поч. Күчүк авылында Осоавиахим сафларында 80 кеше член булып тора, шулардан ворошиловча атучы һәм ПВХО значкистлары саны да байтак.

Кукмарадагы икенче номерлы урта мәктәптә Осоавиахимның башлангыч оешмасында 190 кеше член булып тора. Шулардан 120 кеше оборона значекларына нормалар тапшырдылар.

Партия, комсомол оешмалары җитәкчеләре оборона эшен оештыруда, хәрби белем өйрәнүдә башкаларга үрнәк күрсәтәләр. Мәсәлән, Мәчкәрә авылында партоешма секретаре Садыйков һәм комсомол оешмасы секретаре Бикмуллин, Кукмара урта мәктәбе янындагы комсомол оешмасы секретаре Сольников иптәшләрнең икешәр-өчәр оборона значеклары бар.

*Солтанов.*

# МАШИНАЛАРНЫ РЕМОНТЛАУ СЫЙФАТЫН ЯХШЫРТЫЙК

2 нче номерлы мех фабрикасының чимал цехы узган ел производство планын 112,2 процент итеп үтәде. Хезмәт җитештерүчәнлеге, уртача алганда, һәр эшчегә 19,5 процент күтәрелде.

План үтәлешендә һәм хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә машиналар гаять зур урын тоталар.

Менә шуның өчен без цехтагы машиналарның төзек булуына зур әһәмият бирәбез. Строгаль һәм рубильный машиналарга аерым слесарьлар беркеттек. Агымдагы ремонт өчен цехта тагын 2 слесарь, бер механик бар.

Ләкин бездә машиналарның барсы да яхшы эшли дип булмый әле. Январь аенда машиналарның ватылуы узган айларга караганда күбрәк булды. Бу хәл план үтәлешенә дә йогынты ясамый калмады, әлбәттә. Моның сәбәбе фабриканың өлкән механигы иптәш Драгункинның машиналарга планлы рәвештә алдан ясалырга тиешле ремонтларның срогында үткәрелүенә җитәрлек игтибар бирмәвендә. Үткәрелгән ремонтларның сыйфаты да канәгатьләнерлек түгел.

1 нче номерлы күн машинасына 1939 нчы елның 12 нче декабрендә генә капитал ремонт ясалган иде. Ремонтның сыйфаты начар булу аркасында, хәзер бу машина тагын да ремонтка туктатылды. 2 нче номерлы күн машинасы инде бик күп вакытлардан бирле ремонтта ята.

Центрифугалар өчен кирәк булган конус, кагыйдә буларак, күннән эшләнергә тиеш. Ә тәэминат бүлегендә бер вакытта да күн булмый. Шуңа күрә конусларны фанердан ясарга туры килә. Ә фанер конуслар берничә көннән үк тузалар һәм центрифугаларны тагын ремонтка бирергә туры килә.

Цехларда ремонт эшендә эшләүче слесарьлар ремонт өчен кирәк булган инструментлар һәм материаллар белән тулысынча тәэмин ителмиләр. Агач материаллары булмау аркасында 10, 15, 18 нче номерлы баркаслар күп вакыттан бирле ремонт көтеп яталар. Баркасларның һәрберсе пар шланглары белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Ә бездә 18 баркаска бары бер шланг бар.

Машиналарның тоткарсыз эшләүләрен тәэмин итүдә фабриканың механика цехы җитәкчеләре барлык чараларны күрергә тиешләр.

*К. Маслов.*

2 нче мех фабрикасының чимал цехы начальнигы.

## УЙЛАП ТАБУ ТАКДИМНӘРЕННӘН 322 МЕҢ СУМ ЭКОНОМИЯ

Киез итек - фетр фабрикасында (Казан) уйлап табу, рационализация буенча эшчеләрдән һәм инженер-техник работниклардан үткән елны 71 такдим алынды. Шулардан 26 такдим тормышка ашырылды. Бу такдимнәрне тормышка ашыру производствога зур экономия ясау мөмкинлеген бирделәр. Мәсәлән, иптәш Новиков калыпларны механик рәвештә эшләү машинасы уйлап тапты. Бу чараны үткәрү производствога 3.000 сум файда бирде. Балухин, Гатин, Никулин иптәшләр дә кыйммәтле такдимнәр бирделәр. Алардан килгән файда елына 322 мең 182 сум тәшкил итә.

Ләкин фабрика җитәкчеләре уйлап табучыларны тәрбияләү эшенә игтибар биреп җиткермиләр әле. Бирелгән такдимнәр озак тикшерелми яткырылалар. Уйлап табу эшенә бары тик 47 кеше генә катнаша.

Фабриканың партия, профсоюз оешмалары бу әһәмиятле эшкә нык игтибар бирергә тиешләр.

*Халитова.*

## ФИНАНС ЭШЕ АЛДЫНГЫЛАРЫ

Кызыл Армия районының Ишәле һәм Акъяр авыл советлары 1940 нчы елда финанс планын үтәү буенча район күләмендә алда баралар. Финансактивистлары арасында социалистик ярышны киң җәелдерү нәтиҗәсендә, Ишәле авыл советы 1940 нчы елның беренче квартал планын 20 нче январьга 100 процент, Акъяр авыл советы 118 процент итеп үтәделәр.

Моңа кадәр финанс планын үтәү буенча артта калып килгән Каргали авыл советы да үзенең эшендә кискен борылыш ясады һәм беренче квартал планын срогыннан элек арттырып үтәде. Каргали авыл советының 5 кешедән торган финанс активистлары бригадасы Ишәле, Чаллы Башы һәм Шахмай авыл советларына социалистик ярдәм оештырып, бу авылларда да финанс туплау буенча беренче квартал планының 20 нче январьга 100 процент итеп үтәлүенә ирештеләр.

*Г. Шәрәфиев.*

## ПЛАН ҮТӘЛМИ

Кызыл Юл районы 1940 нчы елның январь ае финанс планын үтәмәде. Апас, Сап, Пшәнгәр авыл советлары өченче бишьеллык (икенче ел чыгарылыш) заемы облигацияләре буенча взнослар җыю һәм гомумән финанс туплау эшендә аеруча начар эшлиләр.

Сап авыл советында әле шушы көнгә кадәр дәүләт страхованиесе, авыл хуҗалыгы налогы һәм башка төрле түләүләр буенча 1939 нчы елгы недоимкаларның җыелып беткәне юк. Заем взнослары җыю буенча беренче квартал планы 1 нче февральгә бары 10 процентка үтәлгән. Авыл советы председателе иптәш Исмагыйлев колхозчылар арасында масса-аңлату эшләрен җәелдерү һәм авыл советы членнарын финанс туплау планын үтәүгә тарту мәсьәләсе белән җитәрлек шөгыльләнми.

Бу кимчелекләр якын арада бетерелергә, финанс планын тулы үтәү өчен барлык чаралар күрелергә тиеш.

*А. Сафин.*

## УҢЫШЛАР БЕЛӘН МАСАЮНЫҢ КҮҢЕЛСЕЗ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Язу машиналары заводы үткән елда зур уңышларга иреште. Завод коллективы Казан предприятиеләре арасында Сталинчыл Өченче Бишьеллык исемендәге социалистик ярышны оештыруда инициатор булды. Бу ярышта алган йөкләмәләрен коллектив намус белән башкарды. Ул ярты еллык планны вактыннан элек арттырып үтәде, планнан тыш илебезгә 262 данә язу машинасы бирде. Бу уңышлары өчен завод Татарстан Җирле Промышленность Халык Комиссариатының күчмә кызыл байрагы белән бүләкләнде.

Кызганычка каршы, завод үзенең бу уңышларын ныгыта алмады, ул артка чигенде. Январь аенда заводның бер генә цехы да планын үти алмады. Февраль аенда да сизелерлек борылыш күренми әле. Беренче декада планы завод буенча 90,5 процент кына үтәлде. Мондый хурлыклы эшне нәрсә белән аңлатырга соң?

Барыннан да элек, җитәкчеләрнең узган елгы уңышлар белән масаюлары, ирешкән уңышларны ныгыту өчен тиешле шартлар тудыру турында уйламаулары белән аңлатырга кирәк. Нормаль эшләү өчен кирәкле булган материалларны хәзерләү турында дирекциягә узган елның декабрь аенда ук әйтелгән иде. Ләкин дирекция бу сигналларга үз вактында игтибар бирмәде һәм шуның нәтиҗәсендә, цехларны материал белән тәэмин итүдә өзеклек туды.

Заводның иң эре цехларыннан берсе—механика цехы соңгы вакытларда аеруча начар эшли. Ә бит бу цехның эшенә заводның барлык эше бәйләнгән. Монда хөкем сөргән таркалганлык, борыла алмаучылык күренешләре цех начальнигы иптәш Солдатенковны һич борчымый. Мәсәлән, револьвер бүлегендә, аеруча су белән эшли торган станоклар буенча, брак 70 процентка җитә. Контролерлар бу аяныч хәлгә карата килешүчәнлек күрсәтәләр.

Механика цехында гүзәл эш үрнәкләре күрсәтүче стахановчылар һәм участкылар аз түгел. Мәсәлән, танылган стахановчылардан Галимова, Бенедиктов, Баландин, Дмитриев, Мансуров иптәшләр һәм Иванова, Матвеев участкылары яхшы эш үрнәкләре күрсәтәләр. Ләкин аларның бай тәҗрибәләре өйрәнелми, артта калучыларга күчерелми.

Җыю цехы да һич канәгатьләнерлек эшлими. Ул январь аенда гына да 100 дән артык машина биреп җиткермәде. Цех начальнигы иптәш Шәмсеттинов моның сәбәбен механика цехына аудармакчы була. Ләкин шул ук вакытта цехның эчке мөмкинлекләреннән файдаланылмый. Монда детальләрне бозу зур урын алган. Мәсәлән, 24 нче январьда 11 данә гребенка төзәтү өчен механика цехына яңадан кайтарыла һ. б.

Язу машиналары заводының бу артта калучылыгы якын арада бетерелергә тиеш.

*Г. Кушаев.*



Рождественский МТС ының (Лаиш районы) Павлов бригадасы тракторларга ремонт ясауда норманы 150 процент үти. РӘСЕМДӘ (сулдан уңга): бригадир Г. Г. Павлов, А. М. Полуенов һәм М. А. Архипов иптәшләр.

С. Чиколкин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

## АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ УСТАВЫН БОЗУГА ЮЛ КУЕЛМАСЫН

Авыл хуҗалыгы артеле уставын кабул итүгә быел 17 нче февральдә биш ел тула. Турыдан-туры иптәш Сталин катнашуы белән төзелгән бу бөек документ колхоз төзелешен ныгытуда гаять көчле этәргеч булды һәм булып тора. Уставны тулысынча тормышка ашырган колхозлар зур уңышларга ирештеләр.

Ләкин, кызганычка каршы кайбер колхозларда эшне устав буенча алып баруга һаман да әле җитәрлек әһәмият бирмиләр, уставның бозылуына юл куялар. Мәсәлән, Чепья районының „Город Кижими“ колхозында колхозчыларның хезмәт көннәре ике айдан бирле, „Деомин“ колхозында бер айдан бирле инде колхозчыларның хезмәт кнегәләренә язылмаган. „Беренче Май“ колхозының беренче бригадасында эшкә чыкмаган кешеләргә дә хезмәт көннәре язу фактлары бар. Чепья районының „Социализм“ һәм Киров исемендәге колхозларында, шул ук „Город Кижими“ һәм „Деомин“ колхозларында, Балтач районының „Днепр“, „Кызыл Көч“ колхозларында һәм Калинин исемендәге колхозда йөкле хатыннарга устав буенча тиешле хезмәт көннәре язылмый. Бу ике районның күп колхозларында базарга барганда һәм каралты тирәсе җирләрен эшләгәндә колхоз атларыннан файдаланган өчен колхозчылардан түләү алынмый.

Колхозларда учет эшләрен юлга салу турында СССР Совнаркомының 31 нче январь 1939 нчы ел карары бу районнарның икесендә дә тулысынча үтәлми. Бу карар буенча МТС ларда учет эшләре буенча аерым инструкторлар булырга тиеш иде. Ләкин Балтач МТС ында да һәм шулай ук Чепья районының Димитров исемендәге МТС ында да мондый инструкторлар һаман да булдырылганы юк әле.

Колхозларда доход бүлү эше белән Балтач һәм Чепья район оешмаларының җитәкчеләре аз кызыксыналар. Чепья районының „Велгород“ колхозында колхозчыларны натуралата бүләклиләр. Моның өчен 308 килограмм бодай биргәннәр инде. Болай эшләү авыл хуҗалыгы артеле уставын бозу булып тора.

Авыл хуҗалыгы артеле уставының закон икәнен, ә законны бозучыларның җавапка тартылырга тиеш икәнен Балтач һәм Чепья район оешмалары җитәкчеләре аңлыйлармы икән?

*Х. Н. Насыйбуллин.*

## АРТТА БАРУЧЫ ИКЕ МТС ТУРЫНДА

Алабуга МТС ы һәм шушы райондагы Морт МТС ы тракторларга ремонт ясау буенча 4 нче квартал планын үтәмәделәр. 1940 нчы елның беренче январена бу МТС ларның беренчесе 57 трактор урнына 20 тракторга ремонт ясады; икенчесе дә планны 50 процентка гына үтәде.

Алабуга МТС ы эшчеләренең гомуми җыелышы ремонтның барышын тикшереп, ремонт эшен 20 нче январьга тәгәлләү бурычын билгеләгән иде. Моннан соң эштә кискен борылыш ясалырга тиеш иде. Кызганычка каршы, ул алай булмады.

Тагылма инвентарьга ремонт ясау начар бара. 86 сабанның 22 сенә генә ремонт ясалган. Культиваторларның һәм чәчкечләрнең яртысы гына ремонттан чыккан.

Эш нәрсәдә соң? МТС ремонт сезонын хәзерлексез башлады. Ремонтчылар әле һаман тупланып җиткәне юк. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауда 2 генә кеше эшли.

Дөрес, ремонт эшендә алдынгылар да бар. Мәсәлән, 9 нчы һәм 10 нчы бригадалар (бригадирлары Коростелев һәм Гальцер иптәшләр) үзләренә беркетелгән тракторларга ремонт ясауны тәгәлләделәр. Ләкин МТС җитәкчеләре шундый алдынгыларны күрмиләр, аларның тәҗрибәләрен башкалар арасында уртаклашмыйлар.

Ремонтта эшләүчеләргә уңайлы эш шартлары тудырылмаган. Ягулык булмау сәбәпле, механика цехында эш еш кына тукталып тора, электросварка икешәр көн эшләми тора. 7 нче январьда двигатель көне буе эшләмәде һәм кыру станоклары туктап тордылар. Шунсы гаҗәп: бу хәл МТС җитәкчеләрен аз гына да борчымый.

Морт МТС ында эшнең барышы мактарлык түгел. Биредә запас частьләр җитешми. Ләкин иске частьләрне яңартуны оештыручы юк.

*С. Сафиуллин.*

## ДАИМИ ЗВЕНОЛАР ОЕШТЫРАБЫЗ

ШӘЙМОРЗА, 11 февраль. (Телефон буенча). Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсеннән соң Буденный районының аерым колхозларында язгы чәчүгә хәзерлек көчәйде. Киңәшмәдә делегат булып катнашкан иптәшләр анда алган тәҗрибәләрен колхозларда практик эшкә ашыралар, башкаларга ярдәм итәләр. Киңәшмә делегаты, „Земледелец“ колхозының звено башлыгы Михайл иптәш Малов үз звеносында эшне шактый яхшыртты. Элек басуга тирес чыгару бик акрын бара иде. Хәзер тирес чыгару эше көчәйтелде. Басуга чыгарылган тирес, агрономия кагыйдәләренә туры китереп, өемнәргә өелә. Кар тоту щитлар белән үткәрелә.

„Кызыл Сабанчы“ колхозы председателе иптәш Усманов колхозга кайткач, киңәшмәдә каралган мәсьәләләр һәм язгы чәчүгә хәзерлекнең барышы колхозчыларның гомуми җыелышында тикшерелде. Колхозчылар киңәшмә куйган бурычларны тулысынча үтәү өчен барлык чараларны күрәчәкләрен белдерделәр. Һәр гектардан 100 пот иген уңышы алу турында йөкләмә алынды. Агротехника чараларын үткәрүдә сизелерлек борылыш ясалды. Кар тоту планы 100 процент үтәлде, басуга 1.280 йөк тирес чыгарылды, машиналарга ремонт ясау тәгәлләнде.

Хәзер барлык колхозларда да даими звенолар оештырыла. Бу эштә колхозларга агрономнар зур булышлык итәләр. 12 колхозда звенолар төзү тәгәлләнде инде. 9 колхозда ефремовчы звенолар оештырылды.

*Ш. Сагдеев.*

Район җир бүлеге мөдире.

## Язарга, сөйләнергә яратучылар

Күптән түгел Кама Тамагы районы кырчылык алдынгыларының район киңәшмәсе булып үтте. Киңәшмә йөзпотчылар хәрәкәте мәсьәләсен тикшерде, районның барлык колхозчыларына мөраҗәгат кабул итте. Монсы яхшы. Ләкин безнең районның байтак колхозларында алган йөкләмәләр турында бик тиз оныталар. Менә „Яңа юл“ колхозы. Бу артельнең колхозчылары конкрет йөкләмәләр алып, Маркс—Ленин исемендәге колхозны социалистик ярышка чакырдылар. Йөкләмәдә авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны тиз көндә тәгәлләү, 600 гектар җирдә кар тоту, басуга 7.600 йөк тирес чыгару, көл, кош тизәге җыю кебек эшләр бар. Колхоз председателе иптәш Миннуллин исә шушы йөкләмә турында онытты да инде. Орлык туплау планы бары 22,5 процентка үтәлгән килеш тора. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау планы да тәмам булганы юк.

Балтач авылы „Октябрь“ колхозында да(председателе Гарифуллин), шундый хәл. Даими звенолар төзелмәгән. Колхозда агротехник юк. Кышкы агротехника чаралары бик начар үтәлә. 5.000 йөк тирес чыгару урнына бары 153 йөк чыгарылган. 180 центнер көл җыю урнына 12 центнер гына җыелган. Фекаль, кош тизәге җыю эшләре дә акрын бара. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауга һәм чәчүлек орлыкларны чистартуга әһәмият бирелми.

*К. Гайнанов.*

Фин ак гвардеецларына каршы сугышларның геройлары

# Пантелей Сарычев

Артиллериядән атышу барганда, күзәтү пункты көтелмәгәндә элемтәне туктатты.

Күзәтү пунктында ике разведчик белән взвод командиры гына бар иде. Батарея белән элемтә өзелгән иде.

Ак финнәр кыю сугышчыларга атака ясарга карар бирделәр.

Бандитлар күзәтү пунктына йөз метр калганда Сарычев һәм Назаров аларның шуышып килүләрен күрделәр.

Назаров каушап калмады һәм команда бирде:

— Сарычев, пулеметка!

Сарычев пулеметны урнаштырды һәм разведчикка хас булган үткен күз белән тау битен карап алды. Тау бите сирәк урман белән капланган иде. Куаклар урынны күзәтүне кыенлаштырдылар.

Ак халатлар кигән финнәр кар өстендә бөтенләй диярлек күренмичә, озын бөҗыра булып үрмәлиләр иде. Бу бөҗра тарайганнан-тарая барды.

Менә халатларның кардан юешләнгәнлекләре дә күренә. Ак бандитларның берсе тиз генә башын күтәрә дә тагын яшеренә. Менә бер офицер, икенчесе, өченчесе күтәрелә. Менә финнәрнең инде бөтен ротасы күтәрелә.

Ярсулы акырынулар, исерек тавышлар урманны яңгыратты: ак финнәрнең кайсылары туп-туры безнең күзәтү пунктына таба йөгерәләр, кайсылары флангларга үрмәләп автоматлардан аталар да аталар.

Сарычев, дәшмичә генә, командирга карады, командир да дәшми генә аңа карап башын селкетте.

Сарычев пулеметка тагын якынырак иелде, аякларын уңайлап куйды һәм кинәт „Максим“ ның дәһшәтле ату тавышлары һаваны дер селкетте. Һөҗүм итеп килүче дошманнар кар өстенә аудылар, ләкин бик тиз күтәрелделәр һәм тагын һөҗүм башладылар.

Алар кычкыралар, ниндидер иләмсез тавышлар белән акыралар, аталар, гранаталар ыргыталар.

Бу эшләрнең берсендә дә тактика артык күренми иде, ләкин шулай да, ничек кенә санасаң да, бер якта ике кеше, икенче якта бөтен бер рота. Сарычев белән Назаровның һәлак булуы котылгысыз иде.

Сарычев гаять зур тынычлык белән ак финнәр өстенә пулеметтан ут яудырды.

Кинәт дошманнар каушадылар. Алар икеләнергә һәм соңыннан чигенергә тотындылар.

Сарычев әле сугышның бетмәгәнлеген белде. Дошман хәл җыячак, сафларын тәртипкә китерәчәк, беренче атаканың ялгышын искә алачак һәм икенче тапкыр акыллырак булачак.

— Сарычев, стволыңны кара!..

Чыннан да, пулеметның стволы кып-кызыл булган иде. Сарычев аны кар белән күмде. Кар эри, пышылдый, кар кисәкләре стволга ябышалар да күз ачып йомганчы эриләр.

Финнәр тагын атакага чыктылар. Сугышчан большевистик машинаның сугыш җыры тагын яңгырады. Пуләнең карга төшүен күрсәтә торган билгеләр бөтенләй юк иде, алар дошманны кыралар иде.

Хәзер дошман түзә алмас һәм паникага бирелеп кача башлар кебек күренде,—ләкин...

Ләкин пулеметның дулосы тагын кып-кызыл булып кыза. Аны суытып торырга вакыт юк: дошман бөтенләй якын. Кечкенә генә тоткарлыктан да файдаланып, дошман басып керәчәк, үзенең бөтен массасы белән таптап китәчәк һәм Назаров белән Сарычевны кисәкләргә теткәләячәк.

Назаров кул пулеметын китерә. Сарычев аны урнаштыра һәм финнәр бер ут ташкынынннан айнып та җитә алмый икенчесенә эләгәләр. Үтерелгән, яраланган финнәр куак араларына, агач һәм төп араларына, кар өемнәренә авалар.

Офицерларның приказлары да, әшәке сүзләр белән сүгенүләре дә инде ак бандитларга тәэсир итми. Аларның кайберләре, коралларын ташлап, дуңгыз кебек карга кереп яшеренәләр, кайсылары паникага бирелеп теләсә кая аталар, кайсылары таудан йөз түбән тәгәрәп төшәләр, кайсылары куркуга бирелеп, аяк үрә басалар, бер-ике адым атлыйлар да кар өстенә авалар: Сарычев аларны кырып сала.

Тигезсез сугыш бетә. Кызыл Армиянең ике сугышчысы ак финнәрнең бөтен бер ротасын тар-мар итә һәм аларны качарга мәҗбүр итә.

Урман тына. Тавышлар басыла. Үтерелгән финнәр тегендә дә, монда да карга күмелеп тау битендә яталар.

Сарычев, үзенә ышанасы килмәгән кебек, яшеренгән урныннан карый.

Әйе, тауда дошманның җанлы көчләре калмаган!

Шатлыктан Сарычевның йөзе яктырып китте:

— Җиндекмени?!

Взвод командиры да шундый ук тәэсирләнгән тавышсыз караш белән җавап бирә:

— Тәмам җиндек, дус!

Ак финнәр ротасының 50 дән артык кешесе үтерелә.

Шулай итеп, канга сусаган һәм куркак банда безнең ике сугышчыбыздан качарга мәҗбүр булды.

***

Частьнең командованиесе Сарычевның атасына, карт колхозчыга, улының батырлыклары турында хат язды:

„Сезне герой улыгыз белән котлыйбыз. Часть командованиесе аңа ССР Союзының иң югары бүләген бирү турында үтенеч кузгата“.

Хатның күчермәләре Сарычевның туган колхозына һәм Сарычевның үзенә җибәрелделәр.

Бу хатның частька бирелгән күчермәсе батареяләр буйлап сәяхәткә китте.

Сугышчылар аны кычкырып укыйлар, тикшерәләр, герой иптәшкә сокланалар, дошманны Сарычев кыйнаган кебек кыйнарга йөкләмәләр алалар.

*М. Чумандрин.*

## ЕФРЕМОВЧЫ ЗВЕНО

Кызыл Армия районының „Алга № 1“ колхозында ефремовчы звено оештырылды. Звенога стахановчылардан 8 кеше беркетелде. Звено башлыгы итеп иптәш Мөхлисуллин билгеләнде.

Звенога 110 гектар чәчүлек мәйданы беркетелде. Звено членнары агротехника чаралары планын производство киңәшмәсендә тикшереп расладылар. 80 гектар җирдә кар тоту үткәрелде, участкыга 2.000 йөк тирес чыгарыла һәм башка төрле ашламалар җыела.

Звено членнары барсы да агротехника укуына тартылганнар. Занятиеләрне Тат. Ялтан МТС ы агрономы иптәш Николаев үткәрә. Иптәш Николаевның инициативасы белән стахановчылар мәктәбе дә оештырылды. Укуга 23 кеше катнаша. Алар арасында Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашкан колхозчылар бар.

*Х. Рәшитев.*

## КАДРЛАР ХӘЗЕРЛӘҮГӘ ҖАВАПСЫЗ КАРАШ

Чаллы районындагы колхоз кадрлары хәзерләү мәктәбендә күп кенә җитешсезлекләр бар. Урындагы бу җитешсезлекләрне бетерүдә тиешле чара күрү урнына, аерым хәлләрдә мәктәпне таркатуга үзләре сәбәпче булалар. Мәсәлән, шәһәр Советы мәктәпнең укучылар торагын һәм ашханә бинасын башка оешмаларга алып бирде. Нәтиҗәдә, күрше районнардан килеп укучы байтак кына кеше гомуми торак булмау аркасында мәктәпне ташлап китәргә мәҗбүр булды.

Мәктәпнең укытучылары да квартира белән тәэмин ителмәгәннәр. Укытучылар составы бик еш алышынып тора.

Мәктәпкә укучылар җибәрү эшенә район башкарма комитетлары һәм район җир бүлекләре бөтенләй җавапсыз карыйлар. Чаллы районы колхозларыннан 53 укучы урнына бары 30 укучы килде. Алабуга районыннан 85 укучы урнына 12 укучы, Бондюг районыннан 61 укучы урнына бары 9 гына укучы килде. Бу районнарда Наркомзем тарафыннан җибәрелгән план колхозларга җиткерелмәгән.

Бу җитешсезлекләр Татарстан Наркомземына да билгеле. Ләкин аларны бетерү буенча бер төрле дә чара күргәне юк.

*Сөләйманов, Рамазанов.*

## „БОЛЬШЕВИК“ СПОРТ ҖӘМГЫЯТЕНЕҢ БӨТЕНСОЮЗ ЧАҢГЫ ЯРЫШЛАРЫ

„Большевик“ спорт җәмгыятенең январь ахырларында Москвада булып үткән Бөтенсоюз чаңгы ярышларында 26 шәһәр командалары катнашты. Ярышларга Казан командасы да барды.

Ярышларда беренче урынны Москва, икенче урынны Казан, Өченче урынны Куйбышев командалары алдылар. Казан командасында катнашкан иптәш Чукаева хатын-кызлар өчен 5 һәм 10 километр дистанциядә үткәрелгән ярышларда икенче урынны, иптәш Черных өченче һәм дүртенче урынны, ирләр өчен 10 километр дистанциядә үткәрелгән ярышларда Ратников дүртенче урынны, Дроздов унберенче урынны, 30 километр дистанциядә үткәрелгән ярышларда Дроздов дүртенче урынны, Ратников жиденче урынны алдылар.

Казанлылар командасына „Большевик“ спорт җәмгыятенең мактау грамотасы бирелде.

*А. Иванов.*

## ӘКИЯТЧЕЛӘР ТҮГӘРӘГЕ

Казан Укытучылар йортында язучы Фабрициус-Киселева җитәкчелегендә балалар өчен әкият түгәрәге эшли башлады. Түгәрәккә шәһәр укытучылары балаларыннан 30 бала йөри.

Атнага ике тапкыр үткәрелә торган кичәләрдә иптәш Фабрициус-Киселева балаларга әкиятләр сөйли. Ул 200 гә якын әкият белә. 6 нчы февральдә бөек рус язучысы А. С. Пушкин әкиятләреннән балалар иртәлеге үткәрелде. Түгәрәк членнары Гримм, Маршак, Чуковский һәм башкаларның әкиятләрен өйрәнәчәкләр. Шулай ук Ленин—Сталин һәм Кызыл Армия турында да әкиятләр сөйләнәчәк.

Балалар түгәрәккә зур кызыксыну белән йөриләр.

## ҖИЛӘК-ҖИМЕШ БАКЧАСЫННАН 9.079 СУМ ДОХОД

Дөбъяз районы Шыпшык авылы, Чапаев исемендәге колхозның җиләк-җимеш бакчасыннан 1939 нчы елны 9.079 сум доход алынды. 62 яшьлек Фәхреттинов бабайның агачларны яхшы тәрбияләве аркасында, колхоз бу бакчадан алма һәм башка фрукталарны мул алуга иреште.

*Ә. Хәйретдинов.*

## ЯҢА ЯСЛЕЛӘР

Шәһәрдә һәм районнарда балалар бакчаларының һәм яслеләрнең челтәре елдан-ел киңәя бара.

Быел Татарстан районнарында яңа яслеләр төзүгә дәүләт тарафыннан 245 мең сум акча билгеләнде. Бондюгта 80 урынлы, Кукмарада 60 урынлы, Азнакайда 36 урынлы, Мамадыш районының „Пятилетка“ совхозында 40 урынлы яслеләр төзелә. Казанда зур предприятиеләр тарафыннан берничә йөз урынлы яңа яслеләр төзелергә билгеләнде.

Педагогия институты студентлары чаңгы тренировкасында (Морквашта).
Н. Костин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

# КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ҺӘМ ХӘРБИ ДИҢГЕЗ ФЛОТЫНЫҢ XXII ЕЛЛЫГЫ АЛДЫННАН

### СНАЙПЕРЛАР

Осоавиахимның алдынгы район советлары Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгына бүләкләр хәзерлиләр.

Осоавиахимның Алабуга район советы снайперлар хәзерләү мәктәбе ачкан иде. Шушы көннәрдә мәктәпнең беренче чыгарышы булды. Укучылар теоретик һәм практик хәзерлек эшендә отлично һәм яхшы билгеләре алдылар. Педучилище студентларыннан Колпакова, Айташева, провизор Колесников, элемтә работнигы Родионов һәм Моисеев иптәшләр мәктәпне отлично билгеләре белән тәмамладылар.

Допризывниклардан снайперлар хәзерләү өчен Казанда Осоавиахимның Бауман район советы да мәктәп оештырды.

### ВОРОШИЛОВЧА АТЛЫЛАР ХӘЗЕРЛӘҮ

Татарстанның зур предприятиеләре Ворошиловча атлылар хәзерләү түгәрәкләре оештыруга керештеләр. Ленин исемендәге заводта һәм 5 нче номерлы совхозда мондый түгәрәкләрдә занятиеләр башланды инде.

Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының данлыклы юбилее уңае белән 4 нче Ясалма Каучук заводы, Мехкомбинат, Жиркомбинат һәм „Кызыл Шәрык“ заводы янында да шундый ук түгәрәкләр оештырыла. Түгәрәкләргә күбесенчә допризывниклар кабул ителәчәк.

### ПРОТИВОГАЗЛАР КИГӘН ХӘЛДӘ ЭШЛӘҮ

„Спартак“ комбинатының штамповка цехында эшләүче хисап работниклары бер көнне икешәр сәгат противогаз кигән хәлдә эшләделәр. Аларның бу үрнәкләре буенча стахановчы штамповщик Ю. Закиров ике сәгат буе противогаз кигән хәлдә эшләп, дәүләт заказын 200 процент итеп, штамповщиклардан Хисмәтуллин һәм Дончеев иптәшләр заданиеләрен 110 ар процент итеп үтәделәр.

Противогаз киеп эшләгән Шәрафиева (хезмәт буенча экономист), Канарская (цех нормировщигы), Федорова (бухгалтер ярдәмчесе), хисапчылардан—Шитова, Шәйхеттинова, Горячкина, Барашева, Галиәкбәрова, ярдәмче эшче Хәлилев, монтер Галиәкбәров, эшче Әюпова иптәшләр дә үзләренең эшләрен яхшы итеп башкардылар.

Эш беткәннән соң бу иптәшләр Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең еллыгын цехта оборона-масса эшләрен тагын да көчәйтү һәм оборона значекларына нормалар тапшыру белән каршылау турында йөкләмә алдылар.

### БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ ДЕКАДАСЫ

Татарстан Совет Язучылары Союзы, Ленин—Сталин комсомолының X нчы пленумы карарлары нигезендә, шушы елның 5 нче мартыннан башлап татар совет балалар әдәбияты декадасын үткәрергә карар бирде.

Бу декада, балалар әдәбиятының ирешелгән уңышларын популярлаштыру белән бергә, алдагы бурычларга язучылар җәмагатчелегенең фикрен дә тупларга тиеш.

Декада көннәрендә язучыларның Г. Тукай исемендәге кабинетында балалар әдәбиятына багышланып зур җыелыш үткәреләчәк. Бу кичәгә Казандагы язучылар, укытучылар һәм укучылар да катнашачаклар.

Шулай ук балалар әдәбиятына багышланган мондый кичәләрне пионерлар йортында һәм кайбер мәктәпләрдә дә үткәрү күздә тотыла.

„Яш Сталинчы“, „Яш Ленинче“ һәм башка газеталар балалар әдәбиятына багышлап махсус битләр оештырачаклар, аерым китапларга рецензияләр урнаштырачаклар.

Декаданы үткәрү өчен, Г. Хәбибуллин, Г. Гобәй, А. Алиш, А. Әхмәт, Ә. Бикчантаева иптәшләр составында махсус комиссия төзелде.

## ШАХМАТ ЧЕМПИОНАТЫ

### 1 НЧЕ ТУР

Казанның шахмат чемпионы дигән исемне алу өчен көрәш башланды. Турнирда катнашучыларның моңа кадәрге турнирлар белән һич тә чагыштырыла алмаслык көчле составы Косолапов, Хрусталев шикелле күптәнге һәм карт шахматчылардан, Нәҗметдинов, Калчурин, Сайгин шикелле соңгы елларда һәм техника һәм иҗад ягыннан зур югарылыкка күтәрелергә, инде шактый дәрәҗәдә танылырга өлгергән шахматчылардан һәм, ниһаять, Вельтмандер, Кильматов, Хенкин һәм башкалар шикелле үзләренең кискен һәм оста уеннары белән һаман алга үрмәләүче яшь шахматчылардан тора.

Катнашучылар бу көчле составтагы ярышны Татарстанның данлыклы XX еллыгына багышларга карар бирделәр.

12 нче февральдә беренче тур булды. „Наука“ спорт җәмгыяте вәкиле Хенкин белән СССР мастерлыгына кандидат Нәҗметдинов арасында барган партия турнирының иң кызыклы партиясе булды. Каралар белән уйнаучы Нәҗметдинов тиз арада позицияне тигезләүгә ирешә һәм бер кадәр өстенлек алды. Ләкин, аклар бик оста саклandылар һәм караларның атака ясарга омтылулары кире кайтарылды. Соңыннан Нәҗметдинов һәр вакыт шах биреп тору мөмкинлеге алу белән генә ничьяга ирешә. Волга буеның элекке чемпионы Колчурингa яшь шахматчы Нотариус белән кискен көрәш алып барырга туры килде. Бу партия Колчурин өчен уңайлырак хәлдә кичектерелде. Виноградов белән Косолапов арасындагы партия тигез хәлдә кичектерелде. Узган елгы ярышларда Татарстан чемпионлыгын яулап алуга ирешкән Сайгин Щербаковны отты. Хрусталев килмәгәнлектән, аның Вельтмандер белән очрашуы булмады.

Киләсе тур 15 нче февральдә була.

*Хәй.*

## КӨНДӘЛЕК ВАКЫЙГАЛӘР

**Охранник йоклаганда.** Казинторгның 2 нче номерлы магазины (Свердлов урамы) охраннигы Кузнецов төнлә үзенең постын ташлап киткән һәм күршедә ремонт ясала торган магазинга кереп йоклаган. Шул чакта П. И. Свирин дигән карак, магазин тәрәзәсен ватып кереп, 22.000 сумлык мех һәм төрле киемнәр урлаган. Свирин әйберләрне күтәреп барган вакытта, Болак буенда милиция работнигы иптәш Бәширев тарафыннан тотылган. Әйберләрне магазинга кайтарып биргәннәр. Свирин соңгы елларда магазиннардан һәм квартиралардан урлаулар белән шөгыльләнгән һәм әле күптән түгел генә төрмәдән чыгарылган булган.

### БЕЛДЕРҮ

14 нче февральдә кич 6 сәгаттә язучыларның Г. Тукай исемендәге кабинетында (Бауман урамы, 19, Матбугат йорты, 5 нче кат) җыелышы була. Җыелышта, Коми шагыйре И. А. Куратовның иҗады турында иптәш С. Урайскийның докладь була һәм яңа әсәрләр укыла.

**Сталин районындагы 12 нче мәктәптә укучы Нәриман Насрытдинов укучы балаларның республика күләмендә булачак үзешчәнлек сәнгате алимпиадасына хәзерләнә.**

М. Солтанов фотосы.

„СОЮЗКИНОПРОКАТ“НЫҢ ТАТАРСТАН БҮЛЕГЕ
шушы көннәрдә ТАССР кино-экраннарына „Ленфильм“дә эшләнгән
ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП

исемле тавышлы, художестволы яңа фильм бирде.
Картина бүгеннән башлап, „Электро“да күрсәтелә.
РЕЖИССОР—В. ЭЙСЫМОНТ, Г. БЛАУШТЕЙН һәм Г. ВЕНЕЦИАНОВ сценарийсы.
БАШ РОЛЬЛӘРДӘ: республиканың атказанган артисты Б. БЛИНОВ, республиканың атказанган артисты М. ДОМАШЕВА, республиканың атказанган артисты В. ЛУКИН һәм артист Л. ШОСТАК һәм башкалар.
Фильмдә Кызыл флотның эш көне, Совет морякларының геройлыклары һәм батырлыклары, безнең диңгез дәүләтебезнең куәте һәм көче художестволы чагылдырыла.

## ДӘҮЛӘТНЕҢ ӨЧЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫК ЗАЕМЫ

(БЕРЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГАРЫЛЫШЫ)

### Оттырышсыз чыгарылыш буенча отышларның бишенче тиражы белешмә таблицасы

Тираж 1940 нчы ел, 5 һәм 6 нчы февральдә Ферганә шәһәрендә үткәрелде.

Тиражда заемның барлык 61 разряды буенча 96.050.600 сумлык 610.000 отыш уйналды.

Таблицада отышларның 100 сумлык облигациягә чыккан сумасы күрсәтелә. Таблицада күрсәтелгән сума эченә облигациянең үз бәясе дә керә.

**Отышлар түбәндәге серия һәм облигация номерларына чыкты:**

| Серия №№ | Облигация №№ | Отышның күләме (сумнар белән) | Серия №№ | Облигация №№ | Отышның күләме (сумнар белән) | Серия №№ | Облигация №№ | Отышның күләме (сумнар белән) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 40020 | 1—50 | 150 | 46297 | 1—50 | 150 | 53019 | 1—50 | 150 |
| 40298 | 1—50 | 200 | 46330 | 1—50 | 150 | 53387 | 1—50 | 150 |
| 40406 | 44*) | 1.000 | 46468 | 1—50 | 150 | 53444 | 1—50 | 150 |
| 40446 | 40*) | 3.000 | 46648 | 1—50 | 150 | 53588 | 26*) | 500 |
| 40521 | 1—50 | 150 | 46823 | 1—50 | 150 | 53927 | 1—50 | 200 |
| 40543 | 1—50 | 150 | 46875 | 1—50 | 200 | 53994 | 1—50 | 150 |
| 40870 | 1—50 | 150 | 46992 | 05*) | 1.000 | 54483 | 1—50 | 150 |
| 40917 | 1—50 | 150 | 47034 | 1—50 | 200 | 54514 | 04*) | 500 |
| 40921 | 1—50 | 150 | 47086 | 1—50 | 150 | 54549 | 1—50 | 150 |
| 41033 | 43*) | 500 | 47104 | 20*) | 500 | 54676 | 1—50 | 150 |
| 41088 | 1—50 | 150 | 47121 | 1—50 | 200 | 54689 | 46*) | 500 |
| 41185 | 1—50 | 150 | 47227 | 1—50 | 150 | 54992 | 1—50 | 200 |
| 41235 | 1—50 | 150 | 47357 | 1—50 | 150 | 55399 | 1—50 | 150 |
| 41252 | 1—50 | 150 | 47501 | 1—50 | 150 | 55445 | 1—50 | 150 |
| 41271 | 1—50 | 150 | 47507 | 1—50 | 150 | 55511 | 1—50 | 150 |
| 41293 | 1—50 | 150 | 47786 | 1—50 | 150 | 55662 | 15*) | 500 |
| 41340 | 1—50 | 150 | 47835 | 26*) | 500 | 55686 | 1—50 | 200 |
| 41416 | 01*) | 500 | 47920 | 1—50 | 150 | 55700 | 1—50 | 200 |
| 41498 | 47*) | 500 | 47925 | 1—50 | 150 | 55701 | 1—50 | 200 |
| 41553 | 1—50 | 150 | 47983 | 05*) | 500 | 55764 | 24*) | 500 |
| 41719 | 48*) | 500 | 48099 | 1—50 | 150 | 55786 | 1—50 | 200 |
| 41789 | 43*) | 500 | 48182 | 1—50 | 150 | 55802 | 1—50 | 150 |
| 41798 | 1—50 | 150 | 48199 | 1—50 | 150 | 55872 | 1—50 | 200 |
| 41800 | 41*) | 500 | 48223 | 26*) | 500 | 55916 | 1—50 | 150 |
| 41823 | 1—50 | 150 | 48290 | 04*) | 500 | 55960 | 1—50 | 150 |
| 42086 | 11*) | 1.000 | 48395 | 1—50 | 150 | 55976 | 1—50 | 200 |
| 42101 | 1—50 | 200 | 48546 | 1—50 | 150 | 56019 | 1—50 | 150 |
| 42187 | 1—50 | 150 | 48583 | 1—50 | 150 | 56029 | 1—50 | 150 |
| 42250 | 01*) | 500 | 48604 | 40*) | 500 | 56305 | 38*) | 500 |
| 42257 | 1—50 | 150 | 48627 | 49*) | 500 | 56483 | 1—50 | 150 |
| 42309 | 1—50 | 150 | 48823 | 1—50 | 150 | 56493 | 1—50 | 150 |
| 42462 | 1—50 | 200 | 48886 | 1—50 | 150 | 56623 | 1—50 | 150 |
| 42541 | 13*) | 500 | 48902 | 1—50 | 150 | 56691 | 1—50 | 150 |
| 42734 | 1—50 | 150 | 48973 | 1—50 | 150 | 56708 | 1—50 | 150 |
| 42742 | 32*) | 500 | 49062 | 21*) | 500 | 56742 | 1—50 | 150 |
| 42753 | 1—50 | 150 | 49066 | 1—50 | 150 | 56753 | 46*) | 500 |
| 42949 | 14*) | 500 | 49094 | 34*) | 500 | 56827 | 1—50 | 150 |
| 43224 | 1—50 | 150 | 49184 | 1—50 | 150 | 56965 | 1—50 | 150 |
| 43253 | 1—50 | 150 | 49207 | 36*) | 500 | 57197 | 1—50 | 150 |
| 43297 | 1—50 | 200 | 49346 | 1—50 | 150 | 57232 | 1—50 | 150 |
| 43411 | 1—50 | 150 | 49483 | 1—50 | 150 | 57298 | 15*) | 500 |
| 43463 | 1—50 | 150 | 49492 | 1—50 | 150 | 57342 | 1—50 | 150 |
| 43501 | 1—50 | 150 | 49521 | 21*) | 500 | 57368 | 1—50 | 150 |
| 43805 | 1—50 | 150 | 49559 | 1—50 | 200 | 57419 | 1—50 | 200 |
| 44079 | 25*) | 500 | 49823 | 1—50 | 150 | 57841 | 1—55 | 150 |
| 44127 | 1—50 | 200 | 49840 | 1—50 | 150 | 57848 | 1—50 | 150 |
| 44286 | 1—50 | 150 | 50071 | 1—50 | 150 | 57880 | 25*) | 1.000 |
| 44426 | 1—50 | 150 | 50080 | 1—50 | 150 | 57947 | 1—50 | 150 |
| 44445 | 1—50 | 150 | 50152 | 09*) | 500 | 57995 | 47*) | 500 |
| 44459 | 1—50 | 150 | 50266 | 02*) | 500 | 58011 | 1—50 | 150 |
| 44470 | 1—50 | 150 | 50534 | 1—50 | 150 | 58017 | 1—50 | 150 |
| 44478 | 24*) | 500 | 50979 | 28*) | 500 | 58225 | 1—50 | 150 |
| 44637 | 20*) | 500 | 51214 | 1—50 | 150 | 58333 | 07*) | 500 |
| 44680 | 1—50 | 150 | 51287 | 1—50 | 150 | 58858 | 1—50 | 150 |
| 44807 | 1—50 | 200 | 51386 | 1—50 | 150 | 58956 | 1—50 | 150 |
| 44924 | 1—50 | 150 | 51422 | 26*) | 1.000 | 58975 | 1—50 | 150 |
| 44948 | 1—50 | 150 | 51513 | 19*) | 500 | 58976 | 1—50 | 150 |
| 45208 | 1—50 | 150 | 51670 | 36*) | 500 | 58990 | 1—50 | 150 |
| 45248 | 04*) | 500 | 51814 | 1—50 | 150 | 59163 | 28*) | 500 |
| 45567 | 1—50 | 150 | 51914 | 1—50 | 150 | 59177 | 07*) | 500 |
| 45591 | 48*) | 500 | 51950 | 1—50 | 150 | 59231 | 1—50 | 150 |
| 45634 | 1—50 | 150 | 52042 | 1—50 | 150 | 59282 | 33*) | 500 |
| 45872 | 03*) | 500 | 52135 | 1—50 | 150 | 59313 | 1—50 | 150 |
| 45982 | 30*) | 500 | 52165 | 1—50 | 150 | 59542 | 09*) | 500 |
| 46023 | 1—50 | 200 | | | | 59621 | 1—50 | 150 |
| 46027 | 1—50 | 150 | 52670 | 49*) | 500 | 59667 | 31*) | 500 |
| 46188 | 1—50 | 150 | 53012 | 1—50 | 150 | 59839 | 14*) | 500 |

*) Бу серия облигацияләренең калган 49 номеры 150 шәр сум отты.

# ПИТОМНИКЛАРГА ИГТИБАРНЫ КӨЧӘЙТЕРГӘ

Хезмәт ияләренең материаль-культура дәрәҗәләре үсү нәтиҗәсендә, аларның төрле сорт фруктларга, җиләк-җимешкә карата булган сораулары көннән-көн арта. Менә шуңа күрә дә һәрбер колхозда җиләк-җимеш бакчасы булдыру, колхозчыларның каралты тирәсе җирләренең бер өлешендә җимеш агачлары утыртуны оештыру һәрбер районда партия, совет оешмаларының һәм җир органнарының игтибар үзәгендә торырга тиеш булган мәсьәләләрнең берсе ул. ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының чираттагы VIII нче пленумы 1940 нчы елгы язгы чәчүгә хәзерлек турындагы мәсьәлә буенча чыгарган карарында колхозларда, совхозларда һәм колхозчылар хуҗалыгында җиләк-җимеш бакчасы булдыру эшенә гаять зур әһәмият биреп, бу эш буенча конкрет чаралар билгеләде. Карарда: „Якындагы еллар эчендә һәрбер совхозда, колхозда һәм колхозчы хуҗалыгында үзенең җиләк-җимеш бакчасы булсын өчен, бакчачылык эшен җәелдерергә кирәк...“ диелә.

Бу бурычны практик тормышка ашыруда җир органнарына бик зур җаваплылык йөкләнә. Алар бу эшне оештыручы булырга тиеш. Фрукт, җиләк-җимеш хуҗалыгын үстерүдә питомникларның әһәмияте гаять зур. Шунлыктан бу мәсьәләне практик рәвештә хәл итүдә питомниклар зур урын тотарга тиешләр. Хәзерге көндә аерым районнарда гына яшәп килә торган питомниклар алга куелган бурычларны тулысынча хәл итә алмыйлар, шуңа күрә аларның эш мәйданнарын киңәйтергә һәм яңа питомниклар челтәрен арттырырга, һәрбер районда питомниклар оештыру бурычын куярга кирәк.

Питомникларның безнең хуҗалыгыбызда тоткан урны гаять зур икәнлеге һәм аларның доходлылыгы һәр кемгә билгеле. Моны Шөгер районының „Шушма“ колхозы янындагы питомникның кайбер эш үрнәгендә дә ачык күрсәтергә мөмкин. Бу питомник (мөдире ВКП(б) члены иптәш Шәрифҗан Сәлимҗанов) эшли башлауга әле ике генә ел. Шуңа карамастан, социалистик ярышны киң җәелдерү нәтиҗәсендә ул зур уңышларга ирешкән. 1939 нчы елда бу питомник Әлмәт районындагы Нәдер авылының „Зәй“ колхозы питомнигы белән ярышта өстенлек алган һәм үзенең производство планын барлык тармаклар буенча арттырып үтәгән.

Монда җиләк-җимеш тә, яшелчә дә зур доход бирә. 1939 нчы елда колхоз яшелчәдән генә дә 40—50 мең сум доход алган.

„Шушма“ колхозы питомнигы җиләк-җимеш агачлары сатудан 1940 нчы елны колхозга 46.000 сум доход бирүне күздә тота. Эшне яхшы оештырганда доходны тагын да күбрәк алырга мөмкин. Бу питомник 1940 нчы елны 15 мең төп алмагач, 40 мең төп карлыган, 40 мең төп чия, 50 мең төп кура җиләге агачлары сатуны планлаштыра. Район оешмалары тарафыннан тиешле җитәкчелек булганда, хезмәтне дөрес оештырганда һәм социалистик ярышны тагын да киң җәелдергәндә бу питомник үзенең планын арттырып үти алачак. Моның өчен питомникта бөтен мөмкинлекләр бар.

Ләкин Шөгер район җир бүлеге һәрбер колхозда җиләк-җимеш бакчасы булдыру эшенә, аеруча бу питомникка яхшы җитәкчелек итә дип әйтеп булмый әле.

Шөгер районындагы 50 дән артык колхозның бүгенге көнгә бары 18 ндә генә җиләк-җимеш бакчалары бар, ә колхозчылар хуҗалыгында мондый бакчалар бик сирәк. 1939 нчы елны районлагы колхозчыларга бары 678 төп алмагачы сатылган. Эш мондый темп белән барганда, Шөгер районы колхозларында һәм колхозчы хуҗалыкларында җиләк-җимеш бакчалары булдыру эше озакка сузылачак.

Республикабызның күп кенә районнары үзләренең колхозларында җиләк-җимеш бакчалары булдыру өчен кирәк булган агачларны әле хәзергә кадәр ерак булган районнардан китерәләр, моның өчен бик күп расход тотыла, ә күп кенә вакытларда утырту материаллары срогында кайтарылмый. Шуның аркасында җиләк-җимеш бакчалары булдыру планы кайбер районнарда үтәлми кала. Киләчәктә мондый фактларга урын калдырмаска кирәк.

Колхозларда, совхозларда һәм колхозчы хуҗалыкларында якындагы елларда җиләк-җимеш бакчалары булдыру мәсьәләсен хәл итү өчен республикабызның җир органнары, партия, совет оешмалары бу эшкә большевистик җитәкчелек итәргә, бу тармактагы алдынгыларның эш тәҗрибәләрен киң күләмдә популярлаштырырга тиешләр. Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариаты һәм, беренче чиратта, аның яшелчәчелек управлениесе бу өлкәдә үз эшләрен тамрыннан яхшыртырга, районнарга якыннан булышлык итәргә тиешләр.

*И. У.*

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген, 14 нче февральдә
БУЛАК АРТЫ „РЕСПУБЛИКАСЫ“
Талон 116.
17 нче февральдә
КЫЮ КЫЗЛАР
Талон 117.
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
14 һәм 15 нче февральдә
МАСКАРАД
Талоннар: бүген 100 иртәгә 101.
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
БҮГЕН ҺӘМ ҺӘР КӨН
Тулысынча яңа программа
ПОПУЛЯР КОМИК, ҺӘР ТӨРЛЕ ХАЙВАННАРНЫ ӨЙРӘТҮЧЕ,
РСФСР ның атказанган артисты, орденлы
М. ЗОЛЛО үзенең антропозоологик труппасы белән.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

| | |
|---|---|
| „ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да. | Яңа фильм ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП |
| „УНИОН“ 11, 1-20, 3-40, 6, 8-20, 10-30 да. | УНБЕР БАШКАЛА |
| „КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да | КОМСОМОЛЬСК |
| „Колхозник“ 4, 6, 8 һәм 10 да. | Инженер Кочинның ялгышуы |
| „ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да. | БРОНЕНОСЕЦ ПОТЕМКИН |
| „ПИОНЕР“ 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 5-30, 7-10, 8-50, 10-30 да. | Көндезге һәм кичке сеансларда ПАТРИОТ Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс. |
| „РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да. | СОҢГЫ ТӨН |
| КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да. | УКЫТУЧЫ |

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 719 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 594.